# Малайларга, кызларга@.RU

Кыш аена да аяк бастык. Яңа ел бәйрәмен дә озак көтәсе калмады. Яшел чыршы, Яңа ел бүләкләре, мандарин исе... Ә Яңа ел бәйрәмен кайчан билгеләп үтә башлаганнар икән, бу хакта уйлап караганыгыз бармы? Бүген сезгә Кыш бабайның кем икәнен ачыкларга мөмкинлек бирәбез.

1. Кайсы патша вакытыннан Яңа елны 1 нче гыйнвардан бәйрәм итә башлаганнар?
   А) Петр I Б) Павел I В) Александр II
2. Аңа чаклы Яңа елны Россиядә кайчан бәйрәм иткәннәр?
   А) 1 марттан Б) 1 июльдән В) 1 сентябрьдән
3. Эскимослар Яңа елны кайчан каршылый?
   А) поляр төн тунгач Б) беренче кар яугач В) 1 гыйнварда
4. Чыршы бизәү иң әүвәл кайсы илдә гадәткә кергән?
   А) Румыниядә Б) Англиядә В) Германиядә
5. Итальян балаларын бу бәйрәм белән кем котлый? Ул ир кешеме, әллә хатын- кызмы?
   А) Ме Аморе Б) Ке Делиция В)Ла Бефана
6. Борынгы Русьта XVIII гасырда Кыш бабай ролен кем “ уйнаган”
   А) Николай Угодник. Б) Архангел Гавриил; В) Святой Петр.

7 Яңа ел чыршысы нәрсәне аңлата?
   А) Христос тууны; Б) галәмне; В) Кыш бабай логотибын.

8 Легенда буенча Кар кызы кем ул ?
   А) элек Кыш бабайны озатып йөрүче кар буранын шулай атаганнар;
   Б) Яңа ел төнендә ярдәм сорап чыккан, кар сылаган кыз бала;
   В) агачларны һәм йортларны кар белән күмәргә ярдәм итүче Кыш бабай оныгы.

9 Россия Кыш бабае кайда яши ?
   А) Мәскәүдә;
   Б) Талбазыда;
   В) Великий Устюгта.

10 Кайсы илдә Яңа елга караганда Раштуа бәйрәменә күбрәк өстенлек бирелә ?
   А) Канадада;
   Б) АКШта;
   В) Австралиядә.

*Тылсымлы төн ике йылды бергә*

*Тоташтырған серле күпер кеүек,*

*Үткән йылдан яҡты киләсәккә*

*Бәхетлеләр генә үтер кеүек.*

*Өмөт менән кеше бәхетле ул,*

*Яҡты уйҙай күңел ҡанатланһын!*

*Хыялдай саф, изге яңылыҡтар*

*Киләһе йылда көн дә ҡабатланһын!*

## *"Яңа Ел белән!"*

Җир шарындагы һәр кеше (Без бит планетада 6 млрд.!) Яңа Елны үзенчә күз алдына килә. Төсе, температурасы, ел мизгеле, төрлечә бәйрәм итү генә түгел, аның әле яңгырашы да аерылып тора!
«Яңа Ел белән!» дип төрле телләрдә әйтү нинди хис-тойгылар уята? Дулкынландыргыч, бер-берсенә охшамаган, яңа, нурлы, бераз авыр, матур бу сүзләр... Үзегез өчен белегез аларны!
Туган җиребез Башкортстанда без "Яңа ел менән!"дибез, чуваш телендә бу" Хаклă тусăм! Эпĕ сана çитсе пыракан Çĕнĕ Çул ячĕпе саламлатăп! " дип яңгырый. Төрекләр якыннарына «Йени Йилиниз Кутлу Олсун! ( Yeni Yiliniz Kutlu Olsun )» диләр. Казахлар: «Жана Жыл Кутты Болсын!» – «Пусть Новый Год будет счастливым!». Гарәп телендә бу: «Куль аам у антум салимоун» ( Kul ' aam u antum salimoun ).
Инглиз телендә инде күпләргә таныш "Happy New Year" колакны иркәли. Кытай телендә – «Чу Шен Тан» ( Chu Shen Tan ). Итальяннар Яңа ел алдыннан «Буон Каподанно! ( Buon Capodanno )» дип кычкыралар һәм йорт җиһазларының искеләрен тәрәзәдән урамга ташлыйлар. Франциядә яшәүчеләр бер-берсен «Бонне Анне! ( Bonne Annee )» дип котлыйлар . Ә немец халкы болай ди – «Прозит Нойяр! ( Prosit Neujahr )». Чехлар «Счастный Новый Рок! ( Scastny Novy Rok )» дип әйтә. Датчаннар: «Гуллюккигь Ниув Яаар! ( Gullukkig Niuw Jaar )». Финнәр аларга: «Оннелиста Юутта Вуотта! ( Onnellista Uutta Vuotta )» дип җавап кайтарыр иде.
Грекларда бераз авыррак, тырышырга туры килер: «Эфтечеезмаенос о Каенуруо хронос! ( Eftecheezmaenos o Kaenooryos hronos )». Ивритта «Ль Шанна Това Тикатеву! ( L ' Shannah Tovah Tikatevu )» дип яңгырый. Индуслар «Нийя Саа Мубарак! ( Niya Saa Moobaarak )» дип сәламлиләр. Ирландлылар борынгы гаэльском телендә – «Блиаин нуа фемхайзе дхуит! ( Bliain nua femhaise dhuit )» диярләр
Поляклар: «Счесливего Новего Року! ( Szczesliwego Nowego Roku )», Португалия халкы бәйрәмне «Фелиз Ано Ново! ( Feliz Ano Novo )» дип каршылый, серблар һәм хорватлар «Счестна нова година! ( Scecna nova godina )» диләр.
Яңгыравы төрлечә. Бәйрәмне күзаллавы да шулай ук. Ә шатлыгы барысы өчен дә бер! Бәлки инде сезгә котлауларның иң ошаганы да бардыр? «Яңа Ел белән!» дигәнне чит телдә ишетеп менә аптырар кунакларыгыз! Бәлки сезгә бәйрәмне шундый стильдә оештырыргадыр? Уйлагыз, сүз эчендә сер яшеренгән! Уңышлар сезгә!

## *Үзең тапкан гына кадерле*

Гади генә бер кыз ул. Елмаюында оялчанлык чагыла. Үзе тыйнак кына сөйләшә. Киләчәктә табиб булырга тели икән, кешеләрне дәвалыйсы килә. Ул — Ильвина Гайнуллина,10 Б” сыйныф укучысы. Гади генә күренсә дә, уңышлары гадиләрдән түгел Ильвинаның — шигырьләр язарга ярата. Шулар белән сезне дә таныштырабыз!

“Кайбер иптәшләрем китап укымауны вакыт юклыкка сылтыйлар. Мин һәр көн йоклар алдыннан бер сәгать китап укырга тырышам. Болай эшләгәндә баш ял итә, көне буе йөреп арган аяклар хәл җыя, ә сөйләмгә, фикерләүгә уңай йогынтысын әйтеп та тормыйм инде” диде безгә Ильвина

Бүгенге көн укучысы компьютер, интернет, телевизордан башка тора алмый. Ләкин болар берсе дә китапны алыштыра алмый. Үзең эзләп тапкан яңалык кына күңелгә ныклап кереп кала.

Тышта суык, чынлап суык...
Юри генә дә түгел,
Җилләр исеп, карлар явып,

Бетә дөня күмелеп!
Тәрәзәләр сурәтләнеп,
Тынып калган бар нәрсә
Буранлап яуган кар аша
Күреп булмый бер нәрсә!

***

Эх! Матур да соң кышкы тәрәз
Сүрәтләре, ичмасам!
Төшерер идем мин дә рәсем
Әгәр рәссам булалсам!!!

## Тәрҗемә конкурсы.

*Татар яки инглиз теленә С.Есенинның “Берёза” шигырен тәрҗемә итегез*

Белая берёза
Под моим окном
Принакрылась снегом,
Точно серебром.

На пушистых ветках
Снежною каймой
Распустились кисти
Белой бахромой.

И стоит берёза
В сонной тишине,
И горят снежинки
В золотом огне

А заря лениво
Обходя кругом,
Обсыпает ветки
Новым серебром.

## Безнең календарь

*Гыйнвар аенда булып үткән истәлекле вакыйгаларны тагын бер тапкыр искә төшереп үтик*

1-5 – Яңа ел бәйрәме .
1-Шагыйрь Һади Такташ туган.
3-Шагыйрь, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты Зөлфәт туган.
- рус шагыйре Николай Рубцов туган.
4 - Язучы, дәүләт эшлеклесе Разил Валиев туган.
- Күренекле рус язучысы А.С. Грибоедов туган.
6 - Драматург Галиәскәр Камал туган.
- Язучы М. Әмир туган.
7 - Раштуа бәйршме.
8 - Химик элементлар таблицасын төзүче галим Д. Менделеев туган.
9 - Язучы Фатих Кәрим туган .
13 Россия матбугаты көне.
17- Рус язучысы һәм драматургы А. П. Чехов туган.
18- Хөсәен Ямашев туган.
25- Россия студентлары көне.
28- Язучы В. Катаевның тууына 110 ел.
29- Рус язучысы, әдәбият буенча Нобельпремиясе лауреаты Б.Л. Пастернак туган.

## Уфада татар укучылары бәйгесе узды

Уфада 11-12 гыйнварда 9-11нче сыйныфларның татар теле һәм әдәбияты республика олимпиадасы узды. Анда республика шәһәр авылларыннан 130лап укучы катнашты. Чара башкаладагы Касыйм Дәүләткилдиев исемендәге республика сынлы сәнгать гимназия-интернатында узды. Элекке елларда олимпиадалар өчәр көн барса, монысы ике көндә эшен тәмамлады.

Беренче көнне чара ачылды һәм төп бәйгеләр узды. Укучылар викторина, инша һәм сәнгатьле укуда белемнәрен һәм сәләтләрен күрсәтте. Һәр өч сыйныф ике төркемгә: милли мәктәпләрдә укучыларга һәм урыс мәктәпләрендә татар телен фән буларак укучылар төркемнәренә бүленеп ярышты. Ягъни, бәйгедә катнашучылар алты төркемгә бүленде.

Икенче көнне укучылар Башкортстандагы билгеле шагыйрь һәм язучылар белән очрашу уздырды. Шул арада бәяләмә төркеме аларның эшләренә йомгак ясады. Очрашуда Башкортстан язучылар берлегенең татар берләшмәсе җитәкчесе, шагыйрә Фәния Габидуллина, шагыйрә һәм галимә Лилия Сәгыйдуллина, шагыйрьләр Радик Хәкимҗан, Руслан Сөләйманов һәм башкалар катнашты. Алар үзләренең мәктәп еллары турында хатирәләре белән бүлеште, туган телнең мөһимлеге турында сөйләде, иҗатлары белән таныштырды.

Филология фәннәре кандидаты, шагыйрә Лилия Сәгыйдуллина: “Республика мәктәпләрендә соңгы унике ел эчендә татар телен өйрәнү 15 процентка кимегән. Шулай дәвам иткән очракта, 35-40 елдан туган телне укыту корытылачак дигән сүз. 1990нчы еллардан башлап республика китапханәләренә Казанда басылган китаплар кайтартылмый, үзебездә чыкканнары исә дистәгә дә тулмый.

Хәлләр коточмалы. Без узган ел “Җанлы сүз” исемле иҗат бәйгесе уздырган идек. Аңа интернет аша укучыларның төрле жанрдагы сигез номинациядәге иҗат җимешләрен җыйдык. Атап әйткәндә: “Шигырь”, “Хикәя”, “Әкият”, “Эссе”, “Нәсер”, “Тәнкыйть”, “Сценарий” һәм “Рәсем” номинацияләре. Куркып кына башлаган идек, чынында, катнашучылар бик күп булып чыкты. Бәйгегә барлыгы 26 районнан 210 укучыдан 300дән артык иҗади эш килде. Бүгенге шартларда да җанлы сүзгә ихтыяҗ бар икән. Шуңа бөтенләй өметне өзәсе килми. Туган телне саклау сездәй фидакарь укытучылар һәм укучылар кулында.”

Очрашудан соң олимпиаданы тантаналы ябу чарасы узды. **Татар мәктәпләре арасында беренче урыннарны 9нчы сыйныфлар арасында Әлшәй районының Трунтаиш мәктәбеннән Аделина Ганиева (укытучысы – Лилия Буранбаева), 10нчы сыйныфлар арасында Кырмыскалы районының Яңа Кыешкы мәктәбеннән Айгөл Әхмәрова (укытучысы – Гөлсинә Гәрәева), 11нче сыйныфлар арасында Илеш районы үзәге Югары Яркәйнең 1нче гимназиясеннән Лиана Галиуллина (укытучысы – Гөлшат Гафарова) алды. Укыту урыс телендә алып барылган мәктәпләрдән беренче урынга 9нчы һәм 10нчы сыйныфлар арасында Бәләбәй татар гимназиясеннән Лүзия Фәттахованың укучылары Илдус Хәбибрахманов һәм Чулпан Арсланова, 11нче сыйныфлар арасында Тәтешле районының Шулган мәктәбеннән Илсөяр Мөхетдинова (укытучысы – Әлфинә Мөхетдинова) лаек булган.** Аларга һәм укытучыларына бүләкләр тапшырылды. Укучыларга бүләкләрне мәгариф министры урынбасары Венера Вәлиева, Башкортстан татарлары милли-мәдәни мохтарияте рәисе Римма Үтәшева, Башкортстан дәүләт университетының

татар филологиясе һәм мәдәнияте кафедрасы мөдире Алмаз Шәйхулов һәм башкалар тапшырды.
Аерым укучыларга Башкортстан татар хатын-кызларының “Сәхибҗамал” оешмасы әгъзалары да үз бүләкләрен тапшырды. Татарстанның Башкортстандагы вәкиле Альберт Максютов укытучыларга һәм чара узган бина җитәкчесе Гөлҗимеш Садыйковага бүләкләр тапшырды.
Укучылары арасында югары уку йортларының татар теле һәм әдәбияты бүлекләренә иң күп студент биргән укытучы да бүләкләнде. Ул Әлшәй районының Трунтаиш мәктәбе укытучысы Лилия Буранбаева. Ул милли кадрлар әзерләүдә республика күләмендә иң нәтиҗәле эшләүче укытучы дип бәяләнде.
Республика олимпиадасының бәяләмә төркеме җитәкчесе, Башкортстан педагогия университетының татар кафедрасы мөдире, филология фәннәре докторы, профессор Илшат Насипов: “Соңгы берничә ел узган олимпиадаларда укучылар югары әзерлекле булуларын күрсәткән иде. Монысында да түбән тәгәрәү юк. Башка еллардан аермалы буларак, урыс мәктәпләреннән килүчеләрнең белемнәре югары булу да күзәтелә. Иншалары хатасыз, ләкин күләмнәре азрак. Быел Тукайның тууына 130 ел тулу сәбәпле, укучылар сәнгатьле итеп аның шигырьләрен сөйләде. Ул шигырьләр арасында мәктәп программаларына кермәгәннәре дә бар иде.
Соңгы елларда егетләр катнашмый иде. Быел дистәгә якын егет килде. Алар Иглин, Күгәрчен, Благовар, Мәләвез, Мишкә, Кушнаренко, Әлшәй районнарыннан, Нефтекама һәм Стәрлетамак шәһәрләреннән. Шуларның икесе – Благовар районы Сарайлы мәктәбенең 9нчы сыйныф укучысы Илшат Рәхмәтуллин (укытучысы – Альфира Мөсәләмова) белән Кушнаренко районы Калтай мәктәбенең 10нчы сыйныф укучысы Таһир Гыйльманов (укытучысы – Зөлфия Нуриева) беренче урыннарны ала алмасалар да, икенче-өченче урыннарга лаек булдылар.
Әлеге бәйгедә җиңүче укучыларны алда тагын бер бәйге – Казанда үтәчәк төбәкара олимпиада көтә. Алар аннан да зур җиңүләр яулап кайтырлар дип өметләнәм.”
Чарада Мифтахетдин Акмулла исемендәге Башкортстан педагогия университеты студентлары да катнашты. Алар укучыларга студент тормышы турында сөйләде, сәнгатьле итеп шигырьләр сөйләде, җырлар башкарды. Олимпиадада катнашкан укучылар арасында да сәләтле җырчылар барлыгы ачыкланды. Алар да ябылу тантанасында чыгыш ясадылар.
Олимпиада ике генә көн узу сәбәпле, укучыларга Уфа белән танышу мөмкинчелеге булмады. Оештыручылар киләчәктә өч көн итеп уздырып, бер кичен Уфа “Нур” татар дәүләт театры тамашасын карап, һөнәр сайлауда булышлык итү өчен Башкорт дәүләт педагогия университеты һәм Башкортстан дәүләт университетларының татар бүлекләре белән таныштыру кирәклеген билгеләде.
Шулай ук иҗат белән шөгыльләнүчеләрне дә ачыклау, аларга язучылар тарафыннан бәя бирү чаралары оештыру кирәклеге билгеләнде.